

Мордовиянен 25 ноябрьдә - Ләмберә, 26 ноябрьдә - Рузаевка районы һәм Рузаевка шәһәрендә, 27 ноябрьдә Ромоданово районында «Татар мәгърифәте коннәре» узды. Чара vзара файдалы хезмәттәшлекне vстерvгә, эшлекле һәм мәдәни багланышларны кинәйтvгә, шулай ук мәгариф олкәсендә эш тәжрибәсе белән уртаклашуга багышланган иде.       Очрашуда мәртәбәле кунаклар - Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгынын милли мәгариф идарәсенен тобәкара хезмәттәшлек секторы модире Гулия Фәргать кызы Мусина; Рамилә Камил кызы Сәгъдиева, Казан федераль университетынын Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтынын гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты, фәннәр кандидаты; Рамилә Әгъзам кызы Абдуллина, Казан шәһәре «Г.Ибраһимов исемендәге 17 нче татар гимназиясе» гимназиясенен туган тел һәм әдәбият укытучысы; Камил Ростәм улы Абдулвахобов, Казан шәһәре «175 нче Гимназия» директоры; Голназ Юныс кызы Котдусова, Тәтеш районынын Байраш топ мәктәбе директоры катнашты.



Мордовия Республикасы мәгариф министры урынбасары Михаил Геннадьевич Аверкин; Мордовия мәгариф министрлыгынын этномәдәни белем бирv буенча белгече Анастасия Викторовна Красильникова, район житәкче урынбасарлары, мәгариф олкәсе хезмәткәрләре, мәктәпләр, балалар бакчалары кунакларны рәхәтләнеп каршы алдылар, милли мәгърифәт олкәсендә ирешкән унышлары белән уртаклаштылар.

2025 елнын 24 ноябрендә Мордовия Республикасы Ләмберә районы Аксён авылы урта мәктәбе кунакларны каршы алды. Регионыбызда татар теле һәм әдәбияты предметларын озак еллар укытып, зур унышларга ирешкән Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укыучысы Фазия Фәрит кызы Боярова очрашудан алган фикерләре белән уртаклашты. Фазия Фәрит кызы:

- Очрашунын программасы тыгыз булды. Конференциядә катнашучылар милли мәгарифне vстерvнен актуаль мәсьәләләре, тел белемендә мәдәниятләр диалогы принцибын тормышка ашыру турында фикер алыштылар. Татарстаннын Тәтеш районы Байраш топ мәктәбе белән Мордовиянен Ләмберә районы Аксен урта мәктәбе арасында «Мәгариф олкәсендә хезмәттәшлек турында тобәкара килешv» имзаланды.

Аксен урта мәктәбе бай программа әзерләгән: Рушания Низаметдин кызы житәкчелегендәге мәктәп хоры чыгышы беркемне битараф калдырмады; Альфия Шәйхетдин кызы Абдюшева житәкчелегендә «Сугыш эзгән гомерләр» спектакле кvнелләрне нечкәртте;  Аэлина



Юнир кызы Абузярова татар теле дәресләрендә интенсив технологияләр кулланып «Татар халык авыз ижаты» темасына ачык дәрес бирде; технологиядән мастер-классны Динара Гаяз кызы Арикова алып барды; Диана Илдар кызы Алькаева житәкчелегендәге

театр тvгәрәгенен кечкенә актерлары «Шалкан» әкиятен сәхнәләштерделәр, 4 класс житәкчесе Рәсимә Хәмзә кызы Юсяева житәкчелегендә залны татар биюенен дәрте белән тулыландырдылар. Барысы да бик кызыклы һәм эчтәлекле иде. Татарстан делегациясе вәкилләре дә эш тәжрибәләре белән уртаклаштылар: бик унышлы мастер-класслар кvрсәттеләр. Укытучыларыбыз vзләре очен яна кvнекмәләр алдылар, укытунын башка методикалары белән таныштылар.
Барыбыз очен матур мизгел турында да әйтәсе килә. «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклау һәм vстерv очен» кvкрәк билгесе белән Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбе укыучысы Фазия Фәрит кызы Боярованы, Татар-Тавла топ мәктәбе укытучысы Альфия Фатих кызы Муртазинаны, Пензятка урта мәктәбе укытучысы Рауза Мукаддәс кызы Юмаеваны, Кадошкино районы Латышовка урта мәктәбе укытучысы Светлана Равил кызы Поташованы бvләкләделәр. Шулай ук татар теле укытыла торган мәктәпләр коллективларына «Рәхмәт хат» лары һәм укучылар очен кирәкле матур китаплар бvләк иттеләр.

Коннен икенче яртысында кунакларны шул ук районнын Пензятка балалар бакчасы каршы алды. Аннары Пензятка урта мәктәбе эш тәжрибәсе белән танышырга момкинчелек тудырылды. Регионара олимпиадаларында һәм мастер-классларында, Мордовиядә танылган татар теле һәм әдәбияты укытучыларынын берсе Рауза Мукаддәс кызы Юмаева Әниләр коненә багышлап «Хатын-кыз бизәнv әйберләрендә татар милли орнаменты – татар брошкасы» дигән мастер-класс vткәрде. Чарада, әниләргә бvләк йозеннән, әлеге мәк-тәпне тәмамлаган Радмир Салякаев аналарга багышланган жыр жырлады. Мәктәп буенча һәм «Хәтер» хәрби дан мәктәп музеенда Рита Рафик кызы Аюпова белән Рияна Ринат кызы Батршина vткәргән эчтәлекле экскурсияләр кызыклы булды.
25нче ноябрьдә Мордовиядә татар мәгъфәте коннәре Рузаевка районында дәвам итте. Мордовиянен Атказанган мәгариф хезмәткәре исемен йорткән мәктәп директоры Флора Ахметжан кызы Шамонова кунакларны мәктәп белән таныштырды һәм Шәриф Камал музеенда экскурсияне дә алып барды. Мәктәптәге тирән эчтәлекле татар теле һәм әдәбияты кабинетында рәсемнәр кvргәзмәсе оештырылган иде, «Бит21» китапханәсенен әйдәп баручы белгече Ләйлә Рафаиль кызы Саляева милли лалә орнаменты белән әйберләрне бизәv буенча мастер-класс vткәрде, Татар Пешлә авылы клубы «Сандугачлар» ансамбле «Туган ягыма кайтам» жырын хисле башкардылар. Татар Пешлә урта мәктәбендә татар мәгърифәте коннәре тирән эчтәлекле һәм унышлы vтте.

Эшлекле очрашуда «Мәгариф олкәсендә хезмәттәшлек турында тобәкара килешv» имзаланды. Гулия Фәргать кызы регионара чараларда vзен таныткан, Мордовиядә татар теле һәм әдәбияты укытучылары арасында зур унышларга ирешкән, кvпторле бvләкләр иясе, тырыш һәм булдыклы укытучы Сания Спартак кызы Саляевага мактау сvзләре әйтеп бvләккә китап томнары тапшырды. Шулай ук Татар Пешлә мәктәбе коллективына «Рәхмәт хат»ы һәм балалар очен кирәкле матур китаплар, калфак-тvбәтәйләр, камзуллар бvләк итте ул.
Татар мәгърифәте коннәре Рузаевка районы Татар Пешләсе авылы «Балачак» балалар бакчасы белән танышу-сәяхәт белән дәвам итте. Бакча житәкчесе Галия Рафаил кызы

Саитова балалар белән милли мәдәният, мәгариф олкәсендә башкарган эшләре турында сойләде, Диана Рәшит кызы Муратова житәкчелегендә «Кояш нурлары» балалар тvгәрәгендә сәхнәләштерелгән «Оч кыз» әкиятеннән озекне кvрсәттеләр. Әниләр коненә багышлап «Яраткан әниемә» дип исемләнгән агачтан ясалган лаләне буяп кунакларга һәм әниләренә тапшырдылар. Ә кунаклар бакчада куллану очен бик кvп әкиятләр, буяу очен китаплар бvләк иткәннәр. Аннары Татарстан кунакларын Рузаевка шәһәренен 5 урта мәктәбе, Яшьләр vзәге каршы алды.



Очрашунын  оченче конендә Татарстан делегатларын Ромоданово районы Белозерье урта мәктәбе һәм авыл балалар бакчасы каршы алды. Башта балалар бакчасы буенча экскурсия vтте, аннары кечкенә концертта балалар «Әпипә»не биеделәр, «Әниемә» жырын башкардылар, патриотик татарча флешмоб vткәреп кунакларны соклaндырдылар. Фатима Рашид кызы Мякушева дәрес-занятиесендә балалар белән татар халык әкиятләрен сойләделәр. Белозерье авылынын башлангыч мәктәбендә кунаклар укучылар белән аралаштылар, татар теле дәресендә булдылар, мәктәп музеенда ата-бабаларынын борынгы конкvреш әйберләрен карадылар. Топ һәм урта мәктәп укучылары, Акилә Абдулбари кызы Сафарова житәкчелегендә, «Солдат хатлары» театральләштерелгән чара кvрсәттеләр, шулай ук Акилә Абдулбари кызы 7А сыйныфта ачык дәрес vткәрде, технология укытучысы Нурия Хайдәр кызы Айзатуллина укучылар белән бисердан милли бизәкләр vрделәр. Эчтәлекле очрашу фәйдалы булды. Коннен йомгаклау олешендә Ромоданово районы Белозерье урта мәктәбе белән Казан шәһәре «175 нче Гимназия»се арасында «Мәгариф олкәсендә хезмәттәшлек турында тобәкара килешv» имзаланды. Гулия Фәргать кызы Мусина коллективка һәм Алтар топ мәктәбе коллективына «Рәхмәт хат»лары белән бvләккә китаплар, калфак-тvбәтәйләр, кам-зуллар тапшырды.

Мондый очрашулар гаять моһим: алар тобәкара элемтәләрен ныгытып кына калмый, ә чираттагы тапкыр мәгарифе һәм мәдәнияте халыкларны берләштерvче ин яхшы кvперләр булуын исбатлый. Мондый кvперләр нык һәм дәвамлы булсын.

**Наилә НАСЫРОВА**